## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең Кенәбаш авылы Халык җыены нәтиҗәләре турында**

2020 ел 23 октябрь № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 23 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, «Совет урамындагы юлларны төзекләндергәннән соң , Бөек Ватан сугышы солдатларына истәлек тактасы әзерләгәннән һәм урнаштырганнан соң экономияләнгән 121213 сум (йөз егерме бер мең ике йөз унөч) сум күләмендә гражданнарның үзара салым акчаларын
- Совет, Үзәк, Тау, Урман урамнарындагы юлларны ремонтлау белән бәйле юл полотносын грейдерлау 48259 (кырык сигез мең ике йөз илле тугыз) сум ;
- Бөек Ватан сугышы солдатларына истәлек тактасын 72954 (җитмеш ике мең тугыз йөз илле дүрт) сум эшләп бетерү өчен фадаланырга» риза буласызмы.

Җыенда сайлау хокукына ия булган 239 кешенең, 128 кеше тавыш бирүдә катнашкан. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 128 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең Кенәбаш авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.
2. "Совет урамындагы юлларны төзекләндергәннән соң , Бөек Ватан сугышы солдатларына истәлек тактасы әзерләгәннән һәм урнаштырганнан соң экономияләнгән 121213 сум (йөз егерме бер мең ике йөз унөч) сум күләмендә гражданнарның үзара салым акчаларын
- Совет, Үзәк, Тау, Урман урамнарындагы юлларны ремонтлау белән бәйле юл полотносын грейдерлау 48259 (кырык сигез мең ике йөз илле тугыз) сум ;
- Бөек Ватан сугышы солдатларына истәлек тактасын 72954 (җитмеш ике мең тугыз йөз илле дүрт) сум эшләп бетерү өчен фадаланырга- кабул ителгән дип исәпләргә.
Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының pravo.tatarstan.ru рәсми порталында халыкка игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче:
Балтач муниципаль районы Карадуган
авыл җирлеге башлыгы: Ш. В. Низамиев